**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«18» февраль, 2021 ел № 116

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 02 мартындагы 317 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегия беркетмәсен исәпкә алып, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтү йомгаклары һәм Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга № ПР-3 от 04.01.2002 ел, бурычлары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 02 мартындагы 317 номерлы карары белән расланган Белем бирү оешмасына йөрүче, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» 2 өлешенең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.»

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http:/www.-pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин